КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 июнь г.Казань № 411

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 9 декабрь, 1206 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 9 декабрь, 1206 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче; 2024 ел, 4 июнь, 404 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның өченче абзацында «, хезмәт хакы ставкасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Фәнни оешмалар хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Икенче дәрәҗә фәнни-техник хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Тикшеренүче лаборант | 23 125 |
| | Тикшеренүче стажер | |
| Өченче дәрәҗә фәнни-техник хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тикшеренүче инженер | 23 175 |
| Фәнни хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече фәнни хезмәткәр | 23 325 |
| | Фәнни хезмәткәр | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән фәнни хезмәткәр | 23 525 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Төп фәнни хезмәткәр | 23 625 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән фәнни хезмәткәр | 24 275 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Техник архив, сызым ясау һәм күчермә алу бюросы, компьютер һәм фото, кино җиһазы лабораториясе, оештыру техникасы, элемтә чаралары мөдире (башлыгы) | 23 325 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Аспирантура, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге, башка структур бүлекчә мөдире (башлыгы)* | 23 525 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Фәнни тикшеренү бүлеге (лабораториясе, бүлекчәсе) составына керә торган фәнни-тикшеренү секторы (лабораториясе) мөдире (башлыгы) | 23 625 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фәнни тикшеренү (конструкторлык), эксперт бүлеге (лабора- | 24 275 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ториясе, бүлекчәсе, секторы) мөдире (башлыгы) | |
| | Гыйльми сәркатип | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Аерымланган бүлекчә башлыгы (мөдире) | 58 000 |
| *Өченче – бишенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш. | | |

Фәнни оешмага аерымланган бүлекчә башлыгы урынбасары (мөдире) вазыйфасы кертелгәндә аның база окладь аерымланган бүлекчә башлыгының (мөдиренең) база окладыннан 0,8 күләмендә билгеләнә.

2.2. Профессорлар һәм мөгаллимнәр составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладь күләме, сум |
|---|---|---|
| Профессорлар һәм мөгаллимнәр составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән мөгаллим | 22 625 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Доцент | 23 625 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Профессор | 23 925 |

2.3. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база окладь күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Музей күзәтүчесе | 20 519 |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 20 825 |
| Библиограф | |
| Төп китапханәче | |
| Төп библиограф | |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Рәссам-конструктор | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең житәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | 20 855 |

2.4. Басма массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладды күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә басма массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| - | Компьютерда жыю операторы | 20 795 |
| Икенче дәрәҗә басма массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Корректор | 20 805 |
| | Техник мөхәррир | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Референт | 20 815 |
| Өченче дәрәҗә басма массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Редактор | 20 825 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле редактор | 20 835 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле редактор | 20 845 |
| Дүртенче дәрәҗә басма массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Баш мөхәррир | 20 855 |

2.5. Эшчеләр гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база окладды күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 19 242 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 19 581 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 19 755 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 19 933 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 20 464 |

2.6. Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 19 242 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 19 440 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 19 581 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 19 755 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 19 933 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 20 160 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 20 346 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 20 536 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 20 729 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 20 926 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 21 127 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 21 353 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 22 265 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 22 465 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 22 665»; |

III бүлек исемендә «(хезмәт хакы ставкасы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},»;$$

5.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5.7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_{ysp} = O_d \times \frac{D_{ysp}}{100\%},»;$$

5.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},»;$$

5.10 пунктның егерме тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},»;$$

5.11 пунктның өченче абзацында «окладларны (хезмәт хакы ставкаларын, вазыйфаи окладларны) түләүгә һәм кызыксындыру характерындагы түләүләргә» сүзләрен «вазыйфаи окладларга, кызыксындыру характерындагы түләүләргә һәм эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләргә» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр.»;

6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

монда:

$O_b$ – фәнни оешмалар хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүгә өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт, сәгать;

$H_N$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган хезмәткәрләрнең база окладлары өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү, нормаль хезмәт шартлары булган эшләрнең төрле төрләре өчен билгеләнгән хезмәт өчен түләү белән чагыштырганда, 4 процент күләмендә хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә арттырылган күләмдә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.4 һәм 6.5 пунктлар өстәргә:

«6.4. Нормаль шартлардан читкә тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) бер үк вакытта башкарганда, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

төнлә белән эшләгән һәр сәгатькә нормаль шартлардагы эш белән чагыштырганда арттырылган күләмдә, әмма хезмәт законнарында һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмнәрдән ким булмаган күләмдә түләнә;

хезмәткәрне график буенча аның өчен билгеләнгән ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эшләгән эш өчен –кимендә ике тапкыр күбрәк күләмдә, шул ук вакытта вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә, әгәр

ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эш айлык эш вакыты нормасы чикләрендә башкарылса, окладтан тыш кимендә бер көнлек яки сәгатьлек база ставкасы күләмендә һәм, әгәр эш айлык нормадан күбрәк башкарылса, база окладыннан тыш кимендә ике көнлек яки сәгатьлек ставка күләмендә түләнә;

ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәргә, аның теләгенә карап, башка ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта ял көнендәге яки эш көне булмаган бәйрәм көнендәге эш бер тапкыр күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләү башкарылырга тиеш түгел;

эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен артык түләү эшнең беренче ике сәгате өчен кимендә бер ярым, аннан соңгы сәгатьләре өчен кимендә икеләтә күләмдә башкарыла;

һөнәрләрне (вазыйфаларны) бер үк вакытта башкарганда, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткәндә, эш күләмен арттырганда яки эш урынында вакытлыча булмаган хезмәткәр вазыйфаларын хезмәт шартнамәсендә билгеләнгән эштән азат ителмичә башкарганда, хезмәткәргә өстәмә акча түләнә. Өстәмә түләүнең күләме, өстәмә эшнең эчтәлеген һәм (яисә) күләмен исәпкә алып, хезмәт шартнамәсе яклары белән килештерелеп билгеләнә.

6.5. Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$) фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының (бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш), профессорлар һәм мөгаллимнәр составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган вазыйфалар буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә фәнни оешмада эшләгән өчен билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ – хезмәткәрнең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары | |
| Икенче дәрәҗә фәнни-техник хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 25 |
| Өченче дәрәҗә фәнни-техник хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 25 |
| Фәнни хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 15 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү хезмәткәрләре вазыйфалары | |
| Профессорлар һәм мөгаллимнәр составы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 50». |

2. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин